**КАРАР № 58**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Советы утырышы**

24 ноябрь 2022 ел Күәм авылы

**2016 нчы елның 23 нче апрелендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү**

2002 нче елның 12 нче июнендәге 67-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында"гы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Әтнә муниципаль районының Күәм авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Күәм авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2016 нчы елның 23 нче апрелендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Күәм авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 8 пунктның 3 пунктчасында «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гатауллин